


19 апрельдә Мордовиядә республика Хокvмәте басмасы «Юлдаш» исемле татар ижтимагый-сәяси газетасы чыга башлауга 20 ел тула. Анын турында беренче коннән алып бvгенге конгә кадәр һәр номернын һәрбер мәкаләсен укып баручы тугры дустыбыз Рузаевка районы Татар Пешләсендә гомер итvче, хөрмәтле татар теле һәм татар әдәбияты буенча сәләтле укучылар тәрбияләvче Сания Спартак кызы Саляева сойли.
- 2005 елдан бирле чыга торган «Юлдаш» газетасы тобәгебездә мәдәни-агарту гына тvгел, сәяси әһәмияткә дә ия; ул якташларыбызнын милли һәм кешелек дәрәжәсен ныгытуга ярдәм итә, Мордовия татарларынын мәдәни-тарихи vзенчәлеген дә, республикада кvпмилләтле бердәмлекнен моһим идеалларын да пропагандалый.

Бvгенге кондә ул Мордовиядәге барлык татар халкынын газетасы, алай гына да тvгел, республикабыз татарларынын милли, дәрәжәле газетасы булып тора. Шулай булды халкын, туган телен һәм мәдәниятен, гореф-гадәтләрен яратытып Мордовия тарихында дәvләт газетасынын мина таныш беренче баш мохәррире Альмира Хәмзә кызы Габунова вакытында да. Кешелекле кеше, эшенен профессионалы, Мордовиянен атказанган мәдәният хезмәткәре Альмира Хәмзә кызы Габунова йорәкләребездә мәнге яшәр.
Газетага нигез салынганнан бирле кvп нәрсә vзгәрде: кvләме, полиграфик башкару, публикацияләр тематикасы. Ул топ вакыйгалар, Мордовия Республикасынын данын кvтәргән кешеләр, тарихи юлнын моһим этаплары турында сойли. Без vзебезнен жирлектәге вакыйгаларны, конкvренешне, шәхесләрне, яналыкларны - тогәл мәгълvматны бары тик «Юлдаш» газетасыннан белә алабыз. Ул татарлар очен компас кебек.
«Юлдаш»нын Мордовия Республикасы Главасыннан, РМ Дәvләт Жыелышыннан, башка дәvләт органнарыннан даими рәвештә бvләкләр алуы очраклы тvгел. Газета битләрендә Мордовиядә яшәvче татар халкынын кvпкырлы тормышын тасвирлап, татар телен,

халкыбызнын тарихи хэтерен һэм мэдэни традициялэрен саклау проблемалары кvтэрелэ. Кеше һэм анын язмышы, биографиясе, милли, гомумкешелек асылы – топ темаларнын берничэсе. Шунысы куанычлы, номердан номерга, Мордовиядэ яшэvче, туган тобэкнен социаль-икътисади һэм мэдэни vсешенэ ярдэм итvче татар миллэтенен лаеклы, кызыклы кешелэре дэ тэкъдим ителэ. Яратып укыган газетабызнын vзенчэлеге – моһим вакыйгаларга катнашы булу, кешелэргэ игътибарлы булу, эшкэ профессиональ хезмэт итv һэм объектив булу. Шунын очен дэ миллэттэшлэребезнен кvбесе һэр атнанын чэршэмбе конен тvземсезлек белэн котеп ала һэм газетаны рус, туган татар телебездэ яратып укыйлар. «Юлдаш» газетасынын сайты популярлаша бара. Югарыда санап киткэн темалардан тыш, Россиянен башка тобэклэрендэге һэм доньянын башка иллэрендэге ватандашларыбызнын бvгенге тормышы турында сойли.
Мин «Юлдаш» газетасынын коллективына ижади унышлар, кызыклы очрашулар һэм мэкалэлэр телим. Журналист калэмегез һэрвакыт vткен булсын! Ин моһиме – «Юлдаш» газетасы тагын кvп еллар укучысына килсен һэм республикада топ мэгълvмат кырларынын берсе булсын. Редакциянен баш редакторы, Россиянен атказанган журналисты, Мордовиянен халык шагыйре Камиль Абидулла улы Тангалычев һэм барлык хезмэткэрлэренэ ижади унышлар, сэламэтлек, бэхет һэм эйткэнемчэ, кvбрэк тугрылыклы укучылар телим!